**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
17.08.2022

КАРАР
№ 901

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 25 маендагы 478 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Авыл хуҗалыгын үстерү турында» 2006 елның 29 декабрендәге 264-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Бюджет кодексы» 1998 елның 31 маендагы 145-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 1. «2021-2022 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 25 маендагы 478 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә, яңа редакциядә шәхси ярдәмче хуҗалыкларда сөт өчен мөгезле эре терлек тотуга матди ярдәм күрсәтүгә гражданнарның гаризаларын карау комиссиясе составын расларга (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Хәмзин

**Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 17 августындагы 901 номерлы карарына**
**1 нче кушымта**

**Шәхси ярдәмче хуҗалыкларда сөткә мөгезле эре терлеклек тотуга матди ярдәм күрсәтү өчен гражданнарның гаризаларын карау комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Хәмзин Рафис Рафикович | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе |
| Шәрәфетдинов Ирек Минсалихович | Нурлат муниципаль районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Сатдарова Альбина Равилевна | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Финанс-бюджет палатасы» МКУ рәисе урынбасары, комиссия секретаре (килешү буенча) |
| **Члены комиссии:** | |
| Исмәгыйлева Лилия Дамировна | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Финанс-бюджет палатасы» МКУ рәисе (килешү буенча) |
| Ибраһимова Марина Вячеславовна | Нурлат муниципаль районының Контроль-хисап палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Әхмәтҗанова Татьяна Аркадьевна | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы |
| Авыл җирлекләре башлыклары | Нурлат муниципаль районыныц авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча) |